ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЗАКЛАР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422722, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Казаклар авылы, Совет урамы, 5

СОВЕТ КАЗАКЛАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422722, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Казаклару, ул. Советская, 5

Тел./факс 8(84365) 63-4-30, e-mail: Kazak.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**13 декабрь 2019 ел** **№ 133**

**“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында**

Россия Федерациясе Конституциясе, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезләмәләрен “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, гамәлдә булган башка федераль һәм төбәк законнарына туры китерү максатыннан, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы тарафыннан 2019 елның 16 нчы октябре 122 номерлы карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында” карар проекты турында” муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен истә тотып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставын “Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында”, 2005 елның 21 нче июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә, муниципаль берәмлекләр Уставын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органында теркәргә

3. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын теркәү өчен җаваплы итеп, “Татарстан

Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы Идрисов Р.Х.ны билгеләргә.

4. Әлеге карарның һәм "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын, "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы белән каралган срокларда, ул муниципаль берәмлекләрнең уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы территориаль органыннан кергән көннән 7 көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә бастырып чыгаруын (халыкка җиткерүен) тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар һәм "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы әлеге карарның 4 пункты белән билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә бастырылып чыкканннан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

6. Әлеге карар һәм "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы рәсми рәвештә үз көченә кергәннән вакыттан соң, "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын яңа редакциядә кабул итү турында" (алдагы үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән 10.10.2016 № 38, от 17.10.2017 № 65, от 27.03.2018 № 78, от 14.09.2018 № 93), 2015 елның 24 нче ноябрендәге 14 номерлы Совет карарын һәм яңа редакциядә кабул ителгән, Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы идарәсе тарафыннан 2015 елның 28 декабрендә теркәлгән, дәүләт теркәү № RU 165163122015001 "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын (алдагы үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән 10.10.2016 № 38, от 17.10.2017 № 65, от 27.03.2018 № 78, от 14.09.2018 № 93) үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге Карарны Казаклар авыл җирлеге составына кергән барлык торак пунктларда мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми портылында http://pravo.tatarstan.ru урныштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы Идрисов Р.Х.ка йөкләргә

Совет рәисе,
Җирлек башлыгы Р.Х.Идрисов